# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ
**2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Чыбыклы авыл җирлегенең Суык-Чишмә торак пунктында**

2024 елның 19 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлегендә халык җыены, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Суык-Чишмә авыл җирлегендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чыбыклы авыл җирлеге Суык-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем Инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Үзәк урам юлын ремонтлау һәм вак таш салуга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Чыбыклы авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән..

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Чыбыклы авыл җирлеге башлыгы** **И.Н. Гадершин**